СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«25» октябрь 2021 ел** **№8**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Ташкичү авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылында Иске Кенәр авылы, Г.Тукай урамы, 67 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 16 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 500 сум, 1нче, 2нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү.
- Бульдозер һәм амкадор хезмәтенә түләү.
- Г.Тукай урамында җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Кенәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Иске Кенәр авылы, Г.Тукай урамы, 59 йорт

адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин